**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 31.08.2020** **№ 667**

**2020-2021 уку елында Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында**

2020 елның 01 мартындагы 47-ФЗ номерлы «Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» Федераль Законның 3 статьясының 3п. һәм 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 37 статьясы таләпләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 августындагы 724 нче номерлы «2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» карары, СанПиНның 2.4.5.2409-08 «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга Санитар - эпидемиологик таләпләр» таләпләре нигезендә һәм Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны балансланган кайнар туклану нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты, **КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елның 1 сентябреннән 2021 елның 31 маена кадәр Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары өчен кайнар тукландыру оештырырга.

Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның тукłануы чыгымнарын финанслауга түбәндәгеләрне юнәлтергә:

- гомуми белем бирү оешмаларында көнгә 5-11 сыйныфларның бер укучысына исәпләгәндә республика бюджетының айлык акчалата түләүләре - 2020-2021 уку елының беренче яртыеллыгында 7,70 сум;
- гомуми белем бирү оешмаларының бюджеттан тыш акчалары;
- ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) ирекле кертемнәре;
- күпбалалы гаиләләрнең 5-11 сыйныф укучылары өчен җирле бюджеттан көненә 15,00 сум.

2. 1-4 нче сыйныф укучыларын 51,85 сумлык бушлай бер тапкыр кайнар ризык белән тәэмин итәргә.

3. Укучыларның кайнар туклануын оештыру өчен җаваплылыкны гамәлдәге законнар нигезендә гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә йөкләргә.

4. Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Арча, Биектау районнарында территориаль бүлегенә (Салкова Э.В.) район гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру өчен тәэмин итүчеләр тарафыннан китерелә торган туклану продуктларының сыйфатын даими рәвештә тикшереп торуны тәкъдим итәргә, укучыларны тукландыруны мөстәкыйль оештыручы учреждениеләрдә гамәлдәге законнар нигезендә туклану оештыруның җитештерү контролен тулы күләмдә (шул исәптән лаборатор тикшеренүләр) тәэмин итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУнә район бюджетыннан «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнең сметасы буенча билгеләнгән нормативларга туры китереп, укучыларны тукландыру өчен максатчан чараларны үз вакытында финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

6. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУнә (Әхмәтҗанов Н.К.) кайнар туклану оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны максатчан файдалануны, исәпкә алуны, мәктәп яны участоклары продукциясе исәбеннән ассортиментны һәм мәктәп ашлары рационын баетуны тәэмин итәргә.

7. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин